**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПЕСЧАНО-КОВАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГОМУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422625 с. Песчаные Ковали,
ул. Октябрьская,д.9а
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАИШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КОМЛЫ КОВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422625 с. Комлы Ковал авылы,
ул. Октябрьск урамы, 9 а нчы йорт,
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**2021 елның 12 октябре** **18 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 13 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 - 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта дәүләт адреслар реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмати адреслар системасын эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә кулланыла торган төшенчәләр, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмати адреслар системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 декабрендәге 1221 номерлы карары белән төгәл туры китереп кулланыла.;

1.2. 1.5 пунктының 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында. «Башкарма комитет» сүзен “төзелгән килешү нигезендә, муниципаль район яки авыл җирлеге җирле үзидарә органы” сүзләренә алмаштырырга;

1.4. . 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район Башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы»сүзләренә алмаштырырга.;

1.5. 2.6.4 пунктында”Башкарма комитетның структур бүлекчәсе белән "сүзләрен" муниципаль районның җирле үзидарә органнары белән «башкарма комитет белән " сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының pravo.tatarstan.ru рәсми порталында игълан итәргә, шулай ук муниципаль районның http://laishevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Н.С. Гыйләҗетдинова**